ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге составына керүче Иске Көшкәт авылы торак пунктларында

17 август 2020 ел №2

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Балтач муниципаль районы Иске Көшкәт авылы торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. Гагарин һәм үзәк урамнары арасындагы күперне капиталь ремонтлау өчен җыелган 104306,40 (йөз дә дүрт мең өч йөз дә алты) сум 40 тиен күләмендә үзара салым акчасын Дуслык урамындагы балалар уен мәйданчыгын коймалар белән урнаштыру өчен файдаланырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңгул авыл җирлеге башлыгы
Балтач муниципаль районы
Татарстан Республикасы Р. Ф. Габдрахманов